# ЧИШМӘ БАШЫ

Гыйнвар, 2025 ел

**Социалистик Хезмәт Герое Габдрахманова Стелла Зәкиевна исемендәге Яңа Кенәр урта мәктәбе**



## *Хәерле юл!*

Керде гыйнвар... Илем туфрагына
Тәңкә-тәңкә карлар төшкәндә.
Тик бер теләк: бөтен планетада
Икмәк булсын һәрбер өстәлдә.
Керде гыйнвар... Ул бит безнең өчен
Ак карлары белән кадерле...
Алып барсын сугышларсыз чорга,
Хәерле юл аңа, хәерле!
Керде гыйнвар... Шатлык алып килсен
Җир шарында барлык өйләргә;
Кешелеккә язсын тагын мең ел
Искә алып аны сөйләргә.
Керде гыйнвар... Дәвам итсен безгә
Сугышларсыз яшәр дәверне.
Ак канатлы бураннары белән
Хәерле юл аңа, хәерле!

*(Мөдәррис Әгъләм)*

## *Ярдәм янәшә*

26нчы гыйнвар көнне район башлыгы Нуриев Илшат Габделфәрт улы җитәкчелегендәге гуманитар ярдәм колоннасы махсус херби операция зонасына юлга чыкты.

Гуманитар колонна китәсе билгеле булуга, районның бөтен халкы – олысы, кечесе, оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, ветераннар оешмалары – барысы да көнне төнгә ялгап эшләде. Бу изге эштән безнең мәктәп тә читтә калмады. Укучылар, әти-әниләр, укытучылар, техник хезмәткәрләр тырышлыгы белән 270 пар оекбаш, 170 пар перчатка, күп кенә күләмдә гигиена кирәк-яраклары, медикаментлар, озак саклана торган ашау-эчү әйберләре җыелды. Башлангыч сыйныф укучылары солдат абыйларына хатлар яздылар. Бу хатларда сабыйларның изге теләкләре, эчкерсез соклану хисләре чагыла. Балаларның теләкләре кабул булып, җиңү яулап, егетләребез туган якларына исән-сау әйләнеп кайтырлар дип ышанып калабыз.









## *“Үсеш ноктасы” – авыл мәктәбе үсешенең заманча бренды.*

22нче гыйнвар көнне безнең мәктәптә якын-тирә мәктәп укучылары өчен “Үсеш ноктасы” (“Точка роста”) үзәге педагоглары семинары булып узды. Семинарда Иске Ашыт, Ташкичү, Шурабаш мәктәпләреннән 32 укучы катнашты. Очрашуны мәктәп директоры Зарипов Хәмбәл Хәбил улы сәламләү сүзе белән ачып җибәрде. Аннан соң укучылар ике төркемгә бүленеп, биш төрле мастер-класс карадылар.

-Ватан иминлеген саклау нигезләре (ОБЗР) фәне укытучысы Габдрахманов В.В. укучыларны “беренче ярдәм күрсәтү” алымнары белән таныштырды;

-өстәмә белем бирү укытучысы Сәмигуллин Т.Ф. бер үк вакытта берничә уенчы белән шахмат уйнау сеансы үткәрде;

-математика укытучысы Галәветдинов М.Ф. робототехника белән эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашты;

-информатика фәне укытучысы Фазуллина Э.Н. VR- күзлек һәм Scratch программасы белән таныштырды;

-технология фәне укытучылары Хәбибуллина Г.Р. һәм Габделәхәтов М.Р. бүләккә аю баласы (кызлар) һәм брелок (малайлар) ясарга өйрәттеләр.

Кунаклар бу чарадан канәгать булып һәм бик күп яңалык алып киткәннәрдер дип ышанып калабыз.

*(Әхмәтсалихова Айзилә, 7Асыйныфы укучысы)*







## *Безнең уңышларыбыз*

Укытуны камилләштерү, укучыларның белемгә омтылышын көчәйтү, зыялы балалар тәрбияләү, һәм иң мөһиме, араларыннан иң сәләтлеләрен сайлап алу максатыннан район һәм республика күләмендә төрле олимпиадалар, конкурслар, ярышлар уздырыла. Мондый бәйгеләрдә безнең мәктәп укучылары да даими катнашалар һәм призлы урыннар яулыйлар. Мәсәлән, 11-сыйныф укучысы Мөхәммәтшина Лилия математика фәненнән “Путь к олимпу” республикакүләм олимпиаданың йомгаклау этабында призер булды. Әлеге олимпиадага Лилия 6нчы тапкыр катнашты һәм 6нчы тапкыр призлы урын яулады.

6нчы гыйнвар көнне инглиз теле фәне буенча үткәрелгән “Who is the Best?” уен-викторинада катнашып, 4-сыйныф укучылары 2нче урын яуладылар.

Районкүләм “Полиглот” конкурсында катнашып, 8А-сыйныфы укучысы Вәлиуллина Зилә – 2 нче урын, 5Б-сыйныфы укучысы Шакиров Муса – 3нче урын алды.

19нчы гыйнвар көнне Казанның “Центральный» стадионында регби буенча турнир узды. Республика шәһәрләрен-
нән килгән командалар арасында безнең мәктәп командасы бердәнбер авыл мәктәбеннән килгән команда иде. 2013-14нче елгы уенчыларыбыз – 8нче урын, 2015-16нчы елгы уенчылар командасы - 13нче урынны алып кайттылар.

Мәктәп данын яклап шушы бәйгеләргә катнашкан укучыларга һәм аларны әзерләгән укытучыларга чиксез рәхмәт!







*(Хуҗиәхмәтова Нурзадә,, 7А сыйныфы укучысы)*

## Укучылар иҗаты

### Туган авылым.

Бик тә матур табигатьле
Яңа Кенәрдә торам.
Сөйли китсәм сүзләр җитмәс,
Шактый җирдә дан торткан.
Бик күп спортчы, геройлары
Авылымны таныткан.
Хәтта укыган мәктәбем дә
Герой исеме алган.
Халкы тыныч һәм кунакчыл,
Ярдәмгә гел омтыла.
Кайгыда да, шатлыкта да
Бердәмлек бик тоела.
Яңа паркы, спорт мәйданы,
Мәчет, кибетләре бар.
Авырып китсәң – хастаханә
Барлык шарт тудырылган.
Шушы авылда туганга
Мин бик тә горурланам.
Үз Ватанымны сакларга
Үскәч армиягә дә барам.
*(Мухтаров Адель, 4 сыйныф укучысы)*

## Атналыклар дәвам итә

27-31нче гыйнвар көннәрендә рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле атналыгы булып узды. Атналык кысаларында бик күп кызыклы чаралар: ачык дәресләр, викториналар, интеллектуаль уеннар, шигъри флэшмоб, хәрби җыр конкурслары үтте.











## Тату сыйныф серләре

29нчы гыйнвар көнне безнең мәктәп базасында “Тату сыйныф серләре” республика конкурсының муниципаль этабы булып узды. Бу бәйгенең максаты – ата-аналар комитеты белән белем бирү учреждениеләренең тыгыз элемтәдә булуын, кулга кул тотынып эшләвен ачыклау. Бәйгедә барлыгы 12 мәктәпнең әти-әниләр комитеты катнашты. Безнең мәктәпнең данын Садыйкова Нурфия Камил кызы җитәкләгән 5нче сыйныф укучылары һәм әти-әниләре яклады. Һәрбер команда күргәзмә, визит карточкасы һәм проект яклау белән чыгыш ясадылар. Шушы чыгышларында командалар укучылар, әти-әниләр һәм сыйныф җитәкчесенең бердәмлеген күрсәтергә тырыштылар.

Безнең мәктәп командасы бу бәйгедә 2нче урынны яулады. Без аларны бу җиңүләре белән котлыйбыз. Афәрин!







Мөхәррир – Хәмидуллина А.Ф., редколлегия – 7А сыйныфы укучылары